# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Олы Ачасыр авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2025 елның 5 марты №8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 5 мартында 10 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Олы Ачасыр авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 2024 елның 21 ноябрендәге 5 номерлы карарга (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүгә ризамы?:

- түбәндәге эчтәлектәге 5 пункт өстәргә:

5) Ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратны киртәләү, материаллар сатып алу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета документациясе әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 440 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 266 кеше кертелде, бу 60,4% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 266 катнашучысы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Олы Ачасыр авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Алынган акчаларны, түбәндәге эчтәлектәге 5 пункт өстәп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

5) Ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратны киртәләү, материаллар сатып алу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета документациясе әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру).

4. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.М. Саттаров